БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26 июль 2018 ел № 141

**«Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлар өчен» медале турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы алдында гражданнарның аерым казанышларын тану, аларның районны үстерүгә юнәлдерелгән шәхси эшчәнлеген бүләкләү, иҗади хезмәтне стимуллаштыру һәм иҗтимагый тормышта активлыкны бүләкләү максатыннан, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлар өчен» медален булдырырга.
2. «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлар өчен» медале турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлар өчен» медале турында Нигезләмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район Советы аппараты җитәкчесе И.С.Сабировка йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин